ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ | БОЕРЫК

06.05.2020 | № 196-р

2020 елга гражданнар керемenең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгән максималь күләмен билгеләү методикасы, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында" 2006 ел, 23 июнь, 694 нче карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. 2020 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 718051,62 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 913883,88 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 1174993,56 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1566658,08 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 1958322,6 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 2349987,12 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 2741651,64 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 18924,77 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 12043,03 сум;

1.2.3. өч кеше һәм аннан да күбрәк кешедән торучы гаилә өчен – 10322,60 сум.

2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елга гражданнарның керемenең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында» 2019 елның 21 июнендәге 295-р номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов